**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО**
**КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 **Чирмешән авылы** № 169

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне**
**арендалау килешмәләре буенча аренда түләвен**
**түләүне кичектереп тору шартлары турында**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, **КАРАР БИРӘМ:**

1.Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендә булган муниципаль мөлкәтне (алга таба - муниципаль мөлкәт) арендалау килешмәләре буенча, тәэмин итәргә:
а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән җиде эш көне эчендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү, 2020 елның апрель - июнь айлары өчен, мондый арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән вакытка, кичектерелгән аренда түләүләрен түләү срогы башлану белән 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча;
б) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге күрсәтмә үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.
2. Билгеләргә:
Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча

алдагы чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен кичектереп тору бирелә;
әлеге күрсәтмәнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель - июнь айлары өчен аренда түләвен кичектереп торуны һәм аны тигез өлешләрдә 2020 һәм (яки) 2021 елларда аренда килешүендә каралган срокларда түләүне, шулай ук аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә кичектереп тору бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш.
3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына муниципаль милекне һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча кичектерү биргәндә, әлеге күрсәтмәнең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән нигезләмәләргә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

**Чирмешән муниципаль районы**
**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Н. Шәйдуллин**